**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР
______________

27.01.2020
ПГ-4

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ____________

## Муниципаль хезмәткәргә башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 ел, № 25 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Актаныш муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибен расларга.

2. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Муниципаль районы Башлыгы Э.Н.Фаттахов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 3E0CBB00BCAAF9924C4EA5D220D0C141
Владелец: Фаттахов Энгель Навапович
Действителен с 02.09.2019 до 02.12.2020

Актаныш муниципаль районы
башлыгы карарына
_____________ № ___
1 нче санлы кушымта

**Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәренең башка түләүле эш башкаруы турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү ТӘРТИБЕ**

1. Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан башка түләүле эш (алга таба – тәртип) башкарылуы турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итүнең әлеге тәртибе «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 ел, № 25-ФЗ Федераль законның 11 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Актаныш муниципаль районында коррупция китереп чыгара торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү, Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре (алга таба – муниципаль хезмәткәр) тарафыннан башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү процедурасын билгеләү максатларында эшләнде.

2. Муниципаль хезмәткәр, әгәр бу үз артыннан мәнфәгатьләр конфликтына китермәсә һәм, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда башкасы каралмаса, яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан язма рәвештә башка түләүле эшне башкарырга хокуклы.

3. Муниципаль хезмәткәр башка түләүле эш башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килгән очракта бүтән түләүле эш башкаруны туктатырга тиеш.

4. Бүтән түләүле эш башкаруны планлаштыручы муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирүче) вәкиленә бүтән түләүле эш башкару турында хәбәрнамәне (алга таба – хәбәрнамә) әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә, муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе белән алдан килештерелгән тәртипкә язма рәвештә җибәрә. Күрсәтелгән хәбәрнамә башка түләүле эшне башкара башлаганчы җибәрелергә тиеш.

5. Хәбәрнамә башка түләүле эш башкару турындагы хәбәрнамәләрне теркәү журналына кергән көнне теркәлергә тиеш, ул әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә алып барыла.

6. Хәбәрнамә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) хәбәрнамә кергән көннән өч эш көне эчендә тапшырыла.

7. Яллаучының вәкиле (эш бирүче) муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эш башкаруга каршы килсә, хәбәрнамә бланкында ул муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эше мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин дигән фикерен нигезли.

8. Яллаучы (эш бирүче) вәкилендә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеге турында шик туган очракта, муниципаль хезмәткәрдән башка түләүле эш башкару турында муниципаль хезмәткәрнең хәбәрнамәсе өч көн дәвамында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне

үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмә нигезендә карау өчен җибәрелә.

9. Башка түләүле эш башкару графигы, шулай ук мондый эшне башкару белән бәйле башка йөкләмәләр үзгәргән очракта, муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирүче) вәкиленә әлеге Тәртип нигезендә хәбәр итә.

Актаныш муниципаль районы хезмәткәрләренә
башка түләүле эш башкарулары турында
яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан
хәбәр итү тәртибенә
1 нче санлы кушымта

___________________
*(танышу турында билге)*

_____________________________________
(Ф.И.О., яллаучы (эш бирүче)вәкиле вазыйфасы

_____________________________________
(Ф.И.О.вазыйфаны биләүче муниципаль хезмәткәр)

**Башка түләүле эш башкару турында**
**ХӘБӘРНАМӘ**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, мин "____" ________________ 20 ___ елдан түләүле эшчәнлекне үтәргә җыенам: ____________________________________________________________

*(эшчәнлек төрен күрсәтергә: педагогик, фәнни, иҗади яки башка эшчәнлек)*

____________________________________________________________________ буенча

*(хезмәт килешүе, граждан-хокукый шартнамәсе, авторлык килешүе һ. б.)*

____________________________________________________________________ эчендә

*(башка түләүле эш башкарыла торган оешманың тулы исеме һәм әлеге оешманың адресы)*

_________________________________________________________________ эше буенча

(башкарыла торган эшнең характерын күрсәтү, мәсәлән, «студентларны укыту», «мәкаләләр язу» һ.б.)

мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килүгә йогынты ясамаячак.

«___» __________ 20___ел ____________________ __________________________

( хәбәрнамә җибәрүче зат имзасы) ( имзаны расшифровкалау)

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ

_____________________________________ ______________

(хәбәрнамәне килештергән вазыйфаи затның Ф.И.О, вазыйфасы) (имза, дата)

Журналда теркәлү номеры
Башкару турында хәбәрнамәләрне теркәү
Башка түләүле хезмәт № ____
Хәбәрнамәне теркәү датасы «____» ______________ 20___ ел.

| __________________________ | __________________ |
|---|---|
| ( Хәбәрнамәне теркәгән вазыйфаи затның Ф.И.О.) | (Хәбәрнамәне теркәгән вазыйфаи затның имзасы) |

Актаныш муниципаль районы
хезмәткәрләренә башка түләүле эш
башкарулары турында яллаучы (эш бирүче)
вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибенә
2 нче санлы кушымта

**Башка түләүле эш башкару турында хәбәрнамәләрне теркәү**
**ЖУРНАЛЫ**

| № т/б | Хәбәрнамәне биргән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.О. | Хәбәрнамәне биргән муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасы | Хәбәрнамәне теркәү датасы | Хәбәрнамәнең кыскача эчтәлеге (эшчәнлекнең характеры), башка түләүле эш башкарылачак оешма исеме | Хәбәрнамәне кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.О,имзасы | Искәрмә |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Лист согласования к документу № ПГ-4 от 27.01.2020
Инициатор согласования: Закиева Л.Р. Заместитель начальника юридического отдела
Согласование инициировано: 27.01.2020 08:51

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Салимов Д.З. | | Согласовано 27.01.2020 - 09:21 | - |
| 2 | Хайдарова Л.Г. | | Согласовано 27.01.2020 - 09:34 | - |
| 3 | Фаттахов Э.Н. | | Подписано 27.01.2020 - 09:54 | - |